Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 август 2021 ел № 10

Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Әлмәт шәһәр прокуратурасы бәяләмәсен һәм программаны гамәлгә ашыруга финанслау чыганаклары булмау турында Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы бәяләмәсен, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының законнарга норматив хокукый актларны туры китерү турындагы телдән күрсәтмәсен карап,

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә башкарма комитеты карарының үз көчләрен югалткан дип таныырга:

- «2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 елның 26 февралендәге 4 номерлы

- «Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә башкарма комитетының «2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 елның 26 февралендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 16 мартындагы 5 номерлы.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе һәм Тихоновка авылы торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты җитәкчесе А.Ю. Зарубин